ГЛАВА НУРИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАС
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НӨНӘГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 декабрь 2025 ел № 26

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 17.12.2025 №28 карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 29.05.2020 №136 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча, гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән, гражданнарның фикер алышуларда катнашу хокукларын үтәү максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген Киров өлкәсе белән чиктәш Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 14 январена 11.00 сәгатькә, түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Нөнәгәр авылы, Ленин ур., 97 нче йорт.
2. Гавами тынлауларда тикшерелә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, 2026 елның 13 январена кадәр, түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Нөнәгәр авылы, Г Ленин ур., 97 нче йорт (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге башкарма

комитетының административ бинасы). Консультация өчен телефон: 8(843)68-3-85-35.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), «ХЕЗМӘТ» басма газетасында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән һәм Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә:
   - Нөнәгәр авылы Ленин ур., 97 нче йорт;
   Комаров-Завод авылы, Үзәк урам, 25б йорт;
   - Чутай авылы, Салих Сәйдәшев урамы, 50 нче йорт:
   Тархан поселогы, Үзәк урам, 1енче йорт .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы И.Н.Закиров